# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлеге Новоспасск авыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**16.10.2023** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 16 октябрендә узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде, түбәндәге сорау буенча «Сез 2024 елда Алексеевск муниципаль районының «Лебедино авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге территориясендәге Новоспасск авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан,көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына срокны хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

- җирлек эчендәге юлларга таш түшәү һәм аларны карап тоту;
- территорияне төзекләндерү (агачларны кисү, каты көнкүреш калдыклары контейнерларын сатып алу);
-су белән тәэмин итү системасын карап тоту.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 150 кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 90 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«ЯКЛЫЙМ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 89 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 1 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлегендәге Новоспасск авыл торак пунктында гражданнар җыены булып узды дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга: «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Лебедино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Новоспасск авыл

торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

- җирлек эчендәге юлларга таш түшәү һәм аларны карап тоту;
- территорияне төзекләндерү (агачларны кисү, каты көнкүреш калдыклары контейнерларын сатып алу);
-су белән тәэмин итү системасын карап тоту.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен , кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Лебедино авыл җирлеге Новоспасск авылы мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә , Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Лебедино авыл җирлеге башлыгы ____________________ Тюкарев Ю.И
(имза ) (имзаның расшифровкасы)